| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>САРМАНОВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **Татарстан Республикасы<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КӘҮҖИЯК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15** .10.2019 ел № 18

**Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында урамнарга, паркларга, скверларга, мәйданнарга исемнәр бирү, һәйкәлләр урнаштыру, аларның исемнәрен үзгәртүнең истәлекле билгеләрен кую тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында карар**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставы нигезендә дәүләт, республика, муниципаль район һәм (яки) иҗтимагый мөнәсәбәтләр үсешенә зур өлеш керткән һәм уңай йогынты ясаган күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар турындагы истәлекләрне саклап калу максатларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында урамннарга,паркларга,скверларга,мәйданнарга исемнәр бирү гражданнар истәлеген мәңгеләштерү максатларында һәйкәлләр урнаштыру, аларның исемнәрен үзгәртүнең истәлекле билгеләрен кую тәртибе турында Нигезләмәне раслау (кушымта).

2. Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе составын (кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе турында нигезләмәне расларга.

4. Урамнарга, паркларга, скверларга, мәйданнарга исемнәр бирү, һәйкәлләр, истәлекле билгеләр кую, гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында аларның исемнәрен үзгәртү турында гариза (үтенечнамәләр) формаларын раслау хакында.

5. Оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, предприятиеләргә, оешмаларга һәм тарихи вакыйгаларга исем бирү мәсьәләләрен хәл иткәндә юридик затларга әлеге карарның 1 пункты белән расланган актларга, истәлекләрен мәңгеләштерү күздә тотылган объектларны, шулай ук аларга күрсәтелгән исемнәрне бирү кагыйдәләрен сайлау өлешендә муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр (оешмалар) өчен билгеләнгән критерийларга таянып эш итәргә тәкъдим итәләр.

6. Әлеге карарны Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Кәүҗияк авыл җирлеге Советы Рәисе

Сарман муниципаль районы

Кәүҗияк авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов